| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«УРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 1 марты №3

**Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслаурга (кушымта итеп бирелә).

2.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында муниципаль хокукый актлар кабул итәргә һәм әлеге карарны башкарганда вәкаләтле дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары белән хезмәттәшлекне тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында хәбәр итәргә: Урмышлы авылы, Үзәк урам, 4, Яңа Елховой авылы, Родничная урамы, 22, Бохар авылы, Авангард урамы, 23 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Ф.Хәбибуллин